МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.08.2023 Казан ш № 695

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 23.08.2023 ел, №695 боерыгы белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Бөек Ватан сугышы ветераны таныклыгы (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 5 июлендәге 514 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 06.06.2014 №309, 22.06.2015 №425, 07.06.2016 №317, 08.06.2017 №350, 07.05.2018 №347, 19.09.2018 №892, 09.01.2019 №8, 13.05.2019 №362, 14.11.2019 №1022, 10.02.2020 №84, 14.07.2020 №512, 02.10.2020 №690, 24.02.2021 №102, 23.11.2021 №864, 14.11.2022 №1001, 20.02.2023 №109 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Бөек Ватан сугышы ветераны таныклыгы (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1.2.1 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«1) пенсия белән тәэмин итү Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды органнары тарафыннан башкарыла торган, «Блокадалы Ленинградта яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затлар, «Камалышта калган Севастопольдә яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затлар һәм «Камалышта булган Сталинградта яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затлар;».

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 634 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 09.07.2015 №461, 09.11.2015 №821, 07.06.2016 №317, 20.07.2016 №420, 28.11.2016 №668, 27.02.2017 №104, 08.06.2017 №349, 28.05.2018 №401, 18.09.2018 №857, 04.02.2019 №77, 07.05.2019 №322, 10.09.2019 №689, 14.11.2019 №1021, 24.03.2020 №192, 13.07.2020 №502, 02.10.2020 №691, 24.02.2021 №102, 21.05.2021 №331, 06.08.2021 №567, 01.10.2021 №710, 13.04.2022 №273, 18.11.2022 №1030 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым

категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламентында:

1.2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) гомуми авыру, хезмәттә имгәнү һәм башка сәбәпләр (инвалидность үзләренең хокукка каршы килә торган гамәлләре нәтиҗәсендә барлыкка килгән затлардан тыш) нәтиҗәсендә инвалидлар дип танылган «Блокадалы Ленинградта яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затлар, «Камалышта калган Севастопольдә яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затлар һәм «Камалышта булган Сталинградта яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затлар;»;

2.8.2 пунктның икенче, дүртенче, уникенче абзацларын үз көчен югалткан дип танырга.